Табигать – иң маһир иҗатчы

Искәргәнегез бардыр, кыргый табигатьне төшерүче фотографларның эшләре хәтта ки башка темаларны яктыртучы бик мәшһүр профессионаллар җирлегендә дә аерылып торучан. Алар төшергән сурәтләр ниндидер вакыйганы гына чагылдырып калмый, әүзенә күрә тормыш фәлсәфәсен бәян итә кебек. Олпат язучы Марсель Галиевнең «Шәһри Казан» редакциясенең күргәзмәләр залында ачылган «Тынлык дәшкәндә» дип аталган күргәзмәсе нәкъ менә шушы максатны күздә тота диярсең.

5 БИТ

Ташламалы бәядән языл!

11-21 май, 2017

Абунәче декадасы

П2430 индексы (пәнҗешәмбе саны) – 415 сум 86 тиен

П2395 индексы (атнага өч тапкыр)– 854 сум 28 тиен

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Сишәмбе | 16.05.2017 | №51 (5813)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

Фәрит Мөхәммәтшин:

«БУ – АЛЛА КУШКАН ЭШ»

Кичә Халыкара гаилә көнендә Татарстанның Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин ятим балаларны тәрбиягә алган 80 гаилә белән очрашты.

Эльвира МОЗАФФАР

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

Игелекле гамәлләр кылган мондый гаиләләр белән зур эш алып барылса да, Дәүләт Советында алар беренче тапкыр җыелды.

Дания Гыйләҗева – Яшел Үзән районының Норлат авылыннан. Өлкән участковый булып эшли. Ун бала анасы. Шуларның сигезен тәрбиягә алган. Әле былтыр гына Гыйләҗевләр берьюлы алты бертуган Мухиннарны гаиләләренә кабул иткәннәр.

– Беренче улыбыз Данисны өч яшьлек чагында тәрбиягә алдык. 11 елдан соң, кечкенә улыбызга иптәш булыр дип, тагын бер малай алып кайттык. Былтыр май аенда телефоныма смс хәбәр килде. Норлат балалар йортында тәрбияләнүче Саша исемле малай: «Дания апа, сезгә кунакка килсәм ярыймы?» – дип язган. Нишлим, «Кил», – дидем. Тора-бара ул, рөхсәт белән, бездә куна да башлады. Аннары үзе белән ике туганын ияртеп килде. Ирем Әнәс: «Балаларны болай азаплап йөртеп булмый бит инде, бәлки гаиләгә алырбыз», – дигәч, тәвәкәлләдек. Мухиннар гаиләдә алтау булып чыкты. Аларны бер-берсеннән аерырга теләмәдек. Шул рәвешле, үзебез дә уйламаганда, ишле гаиләле булып куйдык, – ди Дания апа.

Мухиннар, бер ел дигәндә, инде татарча сөйләшергә дә өйрәнгәннәр.

Балалар йортында үскәнгә, алар тормыш мәктәбен узганнар. Бу сабыйларны башкалардан аерып карарга ярамый. Бәхәсләшсәләр, якалашып алсалар да, бер йодрык булып үсәләр. Берсен-берсе беркайчан да кыерсыттырмыйлар. Шушы зур гаиләнең әнисе булу – минем өчен зур горурлык. Балалар йортыннан киткән балаларның 75 проценты әти-әнисенең язмышын кабатлый, диләр.Бу балаларны кеше итеп тәрбияли алсак, олы тормыш юлына бастырсак – бәхетле булыр идек, – ди Дания апа.

Татарстанда тәрбиягә бала алган 1513 гаилә исәпләнә. Аларның 300е күп балалы гаилә булып санала. Бу гаиләләрдә барлыгы 2907 бала тәрбияләнә. Республикада тәрбиягә бала алучы гаиләләр институтының ныклы эшләве нәтиҗәсендә, дүрт балалар йорты ябылган.

Сүз уңаеннан, Норлат балалар йортында соңгы елларда гына 40 бала яңа гаиләле булган. Ни хикмәт, күбесенчә шул балалар йортында эшләүчеләр ятимнәргә гаилә җылысы бүләк итә икән. «Эшсез калырбыз дип тә курыкмыйбыз, балаларның гаиләле булуына сөенәбез генә», – ди 13 бала анасы, Норлат балалар йорты хезмәткәре Рәисә Миңнуллина. Чакырылган әти-әниләр арасында коллегабыз Йолдыз Шәрапова белән ире Сирин дә бар иде. Алар дүрт малайлары янына күптән хыялланган кызлары Әдиләне тәрбиягә алганнар.

Гаиләләр арасында авыру ятимнәрне үз канаты астына сыендырганнар да җитәрлек. Актаныш районының Күҗәкә авылыннан Шәйхетдиновлар гаиләсе хәтта инвалид балаларны аякка бастыра алган.

→ **Ахыры 2нче биттә.**

ТУГАНЛЫК ҖЕПЛӘРЕ

tatarstan.ru

Федераль Сабан туенда

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Әстерханда 17нче Федераль Сабан туенда катнашты.

Бәйрәм алдыннан Рөстәм Миңнеханов белән Әстерхан өлкәсе губернаторы Александр Жилкин Татарстанның кулланма-гамәли сәнгать осталары һәм һөнәрчеләренең күргәзмә-ярминкәсен карады. Үзәк стадионда бәйрәм мәйданы капкасы янында дәрәҗәле кунакларны Россиянең 44 төбәгеннән Әстерхандагы Сабан туена килгән вәкилләр каршылады. Рөстәм Миңнеханов сәхнәдән бәйрәмдәге халыкны сәламләде. Федераль Сабан туен оештырудагы ярдәме өчен, өлкә җитәкчелегенә рәхмәтен җиткерде.

Татарстан Президенты быел Сабантуйның Россиянең 59 төбәгендә һәм 32 чит илдә узачагын хәбәр итте. Киләсе елда Федераль Сабан туен Чуашия Республикасында үткәрү планлаштырылган.

Рөстәм Миңнеханов татар мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә хезмәт өлеше керткән Әстерхан кешеләрен бүләкләде. Әстерхандагы Габдулла Тукай исемендәге мәктәп директорына микроавтобус ачкычы тапшырды.

Россияне Казан аша өйрәнәләр

14-20 май көннәрендә Казанда III Бөтендөнья яшь ватандашлар уеннары була. Әлеге уеннарда дөньяның төрле илләрендә яшәүче рус телле диаспоралардан килгән балалар катнаша. Уен барышында шахмат, өстәл теннисы, мини-футбол, баскетбол, волейбол һәм йөзү буенча ярышлар булачак.

Яшь ватандашлар беренче тапкыр 2015 елның апрелендә Сочида җыелган иде. Анда дөньяның 33 иленнән 15 яшькә кадәрге балалар катнашты. Икенче уен да анда үтте. Хәзер исә уенны оештыручы «Бердәм Россия» партиясе аны Россиянең спорт башкаласы булган Казанга күчермәкче. Безгә дөньяның 46 иленнән 600гә якын бала киләчәк.

Уен үткәрү урыны буларак Казан очраклы сайланмады. Оештыручылар Татарстан башкаласы аша Россиянең уңышларын, бөеклеген күрсәтергә тели.

– Максатыбыз – уеннарны профессиональ дәрәҗәдә үткәрү. Шуңа да без бүген Россиянең төп спорт, мәдәни һәм белем бирү үзәгендә – Казанда җыелдык. Биредә булган иң яхшы спорт объектларын яшьләребезгә дә күрсәтәсе килде, – ди Россия спорт министры урынбасары Марина Томилова.

– Читтә яшәүче балаларны җыю өчен уен формасын тикмәгә генә сайламадык. Спорт теле барысы өчен дә бер. Балалар монда дуслаша, аралаша. Боксчы Николай Валуев, шахматчы Анатолий Карпов кебек дөнья дәрәҗәсендә танылган спортчылар белән очраша, – ди өч тапкыр Олимпия чемпионы депутат Ирина Роднина.

Спорт ярышларыннан тыш, яшьләр тарих, рус теле һәм әдәбияты буенча белем туплаячак. Казан буйлап сәяхәт итеп, Татар мәдәнияте көннәрен үткәрәчәк. Шулай ук алар «Ватандашлар аллеясы» булдырачак, агачлар утыртачак.

Алисә САБИРОВА.

15 майдан Казанда язгы чордагы игелекле эшләр декадасы старт алды. Быелгы уку елы башында беренче сыйныф укучыларына «Игелекле эшләр көндәлеге» («Дневник добрых дел») таратылган иде. Балалар уку елы дәвамында башкарган игелекле гамәлләрен әлеге көндәлеккә язып бардылар.

Игелекле ункөнлек башланды

«Эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә шәһәр Башкарма комитетының балалар һәм яшьләр эшләре буенча комитеты рәисе Айдар Фәизов хәбәр иткәнчә, декада кысаларында, «көндәлек»кә нәтиҗә чыгарыла. Башта беренче сыйныф укучыларыннан иң шәфкатьле бала мәктәпләрдә сайлап алына. Район этабын узган активистларга «Игелек ярминкәсе»ндә мактау грамоталары тапшырылачак. Шәһәр күләмендә җиңүчеләрне мэр Илсур Метшин 23 майда бөтеншәһәр «Соңгы кыңгырау» мәдәни чарасында бүләкләячәк.

«Игелекле Казан» проекты һәм шәһәрнең хәйрия фондлары вәкилләре 18 майда Мәскәүгә Добро Mail.Ru сервисы ел саен үткәрә торган Бөтенроссия конференциясенә бара.

– Казанда 20 майда Кремль яры буенда Legal Run юристларының хәйрия йөгереше оештырыла. Әлеге чарадан кергән акчалар Чулпан Хаматованың «Подари жизнь» хәйрия фондына тапшырыла, – диде Айрат Фәизов.

20 майда 10.00 сәгатьтән 14.00 сәгатькә кадәр Горький исемендәге үзәк мәдәният һәм ял паркында, «Континент» паркында, Горки-Әмәт урманлыгында, Химиклар мәдәният сарае янындагы нәратлыкта «Игелек ярминкәсе» уза. Әлеге хәйрия ярминкәләрендә мәктәп укучыларының кул эшләре, тәм-томнар сатылачак. Кергән акча шәһәрнең хәйрия фондларына күчерелә.

– Ярминкәләр концерткүңел ачу программасы белән тулыландырылды. Игорь Крутойның популяр музыка академиясендә укучылар «Игелекле Казан» проектының гимнын тәүге мәртәбә башкарачак. Казанда академия филиалы, композиторның үзе катнашында, апрель аенда Камалиев проспектындагы 28/9нчы йортта ачылган иде. Анда вокал, хореография, артист осталыгы, битбокс, телевидение-блоггинг иҗат юнәлешләрендә 100гә якын бала укый.

Игелекле эшләр декадасы кысаларында, мәктәп укучылары шәһәр паркларын җыештырырга чыгачак, аз керемлеләр, ветераннар өчен әйберләр җыячак, ялгыз әби-бабайларга булышачак. Бу гамәлләр Россия Иҗтимагый палатасы тарафыннан үткәрелә торган «Игелекле эшләр марафоны» Бөтенроссия акциясендә катнашучы Казан мәктәпләре командаларына эш күрсәткече сыйфатында языла. Айдар Фәизов әйткәнчә, беренчел нәтиҗәләр буенча, Казан – илнең игелекле шәһәрләре рейтингында икенче урында, әлегә беренчелек – Санкт-Петербургта. Тулаем нәтиҗә июнь аенда билгеле булачак.

Казан мэры Илсур Метшин, үзенең фикерләре белән уртаклашканда, игелекле эшләр декадасына зур әһәмият бирде.

– Балаларга теләктәшлек күрсәтик. Хәйрия чараларына мәҗбүриләү булмасын. Башкаларга ярдәм итү теләгән, шәфкатьлелекне балаларда кечкенәдән тәрбиялик, – диде Илсур Метшин.

Дамир БӘДРИЕВ.

Фәрит Мөхәммәтшин:

«Бу – Алла кушкан эш»

→ **Ахыры. Башы 1нче биттә.**

– Без өйдә 20 кеше яшибез. Өч бала үзебезнеке, 13ен тәрбиягә алдык, аларның алтысы – инвалид. Иң кечкенәсенә – бер, олысына 18 яшь. Әти-әни иртә вафат булды, үзебез дә ятимлекнең нәрсә икәнен күреп үскәнгә, бу балаларны яхшы аңлыйбыз, – ди Фәнзилә апа.

Шулай ук Актаныш районыннан килгән Сабитовлар гаиләсендә дә – 10 бала. Җидесе ятимнәр йортыннан алынган. Сигез айлык сабыйны да тәрбиягә алырга курыкмаган алар.

– Балалар күп булган саен, тәрбияләргә җиңелрәк. Мыш-мыш килеп йоклаулары бер музыка кебек яңгырый, – ди Венера апа.

Борчуы да юк түгел. Тузган торак программасы буенча каралган 80 квадрат метр тораклары өчен 3 миллион 300 мең сум түләргә кирәк. Гаиләнең аны түләү мөмкинлеге юк. Шуңа да ул Дәүләт Советы рәисенә ярдәм сорап мөрәҗәгать итте. Мондый фикер, тәкъдимнәр очрашу вакытында шактый яңгырады. Ятим балалар арасында уңышларга ирешкәннәрне махсус стипендия белән бүләкләү, гаиләләргә торак мәсьәләсендә ярдәм күрсәтү дисеңме. Фәрит Мөхәммәтшин, аларның берсен дә игътибарсыз калдырмабыз, дип ышандырды. Бүләкләрсез дә булмый. Талантлы балаларга «Безнең заман герое» билгесе тапшырылды. Ятимнәрне тәрбиягә алган гаиләләр династияләренә рәхмәт хатлары бирелде. Яшел Үзән районы Норлат авылыннан Кашаповлар гаиләсе Фәрит Мөхәммәтшинга балаларның үз куллары белән ясаган агач дага бүләк итте, Бөгелмәдән Красновлар гаиләсе иҗади чыгышы белән таң калдырды.

– Тәрбиягә бала алган гаиләләр – олы йөрәкле кешеләр. Алар картлыкларын уйлап, үзләренә иптәш булсын дип кенә бала алмый. Монда күпкә көчлерәк хис. Алар Алла кушкан эшне үтиләр. Мондый гаиләләрдә аерылышу очраклары да юк. Оясында ни күрсә, очканында шул булыр, диләр. Гаилә җылысын бернинди приют та, мәктәп, училище да алыштыра алмый. Гореф-гадәтләр нәкъ менә гаиләдә саклана, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Бары безнең Татарстанда гына гаиләләрнең шундый нык булуына басым ясады ул.

– Европа илләрендә, балигъ булгач, бала гаиләдән аерылып чыга. Ике арада аралашулар сирәгәя. Әни белән баласы ресторанда очрашсалар да, һәрберсе өчен аерым түли. Ә бездә ничек? Балалардан хәбәр килми торса да, хатыным борчыла башлый. Балаларны, оныкларны шатланып көтеп аласың, шатланып озатасың да. Чөнки бөтен өйнең өстә-аска килә. Ничә яшьтә булсалар да, бала безнең өчен бала булып кала, – диде Фәрит Мөхәммәтшин, елмаеп. «Җәмгыятьнең төп нигезе булган гаиләләрне сакларга кирәк», – дип төгәлләде ул чыгышын.

Сантыйлык өчен салым?

Соңгы елларда Россия депутатлары берсеннән-берсе сәеррәк проектлар, идеяләр тәкъдим итү буенча бәйге ачып җибәргәннәр диярсең. Мединскийның телләр турындагы тәкъдиме, бердәм милләт булдыру идеясе... Иренми санасаң, күп инде... Хәзер милләтләрне чеметкәләүдән туктап, шәхесне кысу яссылыгына күчәргә маташалар бугай. Һәрхәлдә, демография, миграция һәм төбәк үсеше институты директоры Юрий Крупнов тәкъдиме шулайрак уйларга мәҗбүр итә. Анда сүз баласызлардан һәм бер балалылардан дәүләткә салым түләтү турында бара. Әгәр бала табарга сәламәтлеге мөмкинлек бирмәгәннәр бу хакта белешмә китерергә тиеш. Янәсе, бу керем күп балалы гаиләләргә ярдәм итү өчен китәчәк.

Марат КӘБИРОВ

Әлеге тәкъдим Крупнов әфәнденең җир тормышыннан ярыйсы ук ерак яшәвен, демографиягә кагылышлы институтны җитәкләсә дә, бу мәсьәләдә бик сай йөзүен күрсәтә бугай. Бер карасаң, үз эшен белмәгән адәмнәрнең сүзен чынга алырга кирәкми кебек. Әмма дәүләт дәрәҗәсендә тәкъдим ителгәч, мондый ахмаклыкны да игътибарсыз калдырып булмый. Шуңа күрә, артык тирәнгә кереп тормыйча, иң өстә яткан өч нәрсәгә генә тукталып китәм. Әлеге тәкъдимнең ни икәнен аңлау өчен шушы очраклар да җитәдер.

1. Гаилә әгъзаларының кайсыныдыр авыру – аларга бала табарга ярамый. Һәм бөтен акчаларын түгеп дәвалана да торганнардыр. Бу үзе үк фаҗига, мондый кеше үзе үк дәүләт яклавына мохтаҗ. Ләкин шуның урынына, ул төрле медик белешмәләр җыеп, мәртәбәле комиссия алдында үзенең бала таба алмавы өчен акланырга да тиеш буламы? Авыру кешеләрне мәсхәрәләүнең моннан да аяусызрак тагын нинди ысулы бар?

2. Бер бала белән яки бала табарга да өлгермичә тол калган хатын-кыз да шушы категориягә керә ич. Кайгыга юлыгуы гына җитмәгән, ул хәзер салым да түләргә тиеш буламы инде? Әә ул үзе ярдәмгә мохтаҗ түгелме? Бу бит ялгыз аналарны дәүләт дәрәҗәсендә мыскыл итү булып чыга.

3. Гаилә матди яктан тотрыксыз хәлдә. Икенче бала турында уйлау түгел, ә беренчесен үстерү дә зур кыенлыклар тудыра. Һәм болай да авыр хәлдәге гаилә әгъзалары салым түләргә тиеш булып чыгамы?

Һәм әлеге тәкъдимнең иң хәтәр бер ягы: ул «Күп балалы гаиләләргә ярдәм итү кирәкме?» дигән сорау тудыра. Бу очракта җавап бер яклы гына була алмый.

Бер карасаң, бәхәссез кебек инде. Әгәр кеше күп бала тәрбияләп үстерә икән, ул чынлап та мактауга лаек һәм аңа берсүзсез ярдәм итәргә кирәк. Ләкин ярдәм чын мәгънәсендә ярдәм булырга тиеш. Кешенең үз теләге буенча, үз мөмкинлегенә карап.

Югыйсә бездә ярдәм итәргә мәҗбүриләү модасы да кереп бара. Кайсыдыр илгә гуманитар ярдәм җибәрергә туры килсә дә, башка очракларда да халыкның, гадәттә, бюджетникларның икешәр-өчәр-дүртәр йөз акчасын тотып калырга гадәтләнделәр. Мондый «ярдәм» кайсы ягы беләндер рэкетирлыкны хәтерләтә һәм кешеләрдә бары тик тискәре мөнәсәбәт кенә уята.

ФИКЕР

Әлеге тәкъдим дә әнә шушы «мәҗбүр итү» принцибына корылган. Ә мәҗбүр итү һәрвакыт каршылык уята: «Ни өчен аңа мин ярдәм итәргә тиеш?»

Һәм бу сорауның нигезе бар. Баланы кеше Ватан кушкан өчен түгел, ә үз теләгенә һәм мөмкинлекләренә карап табарга тиеш. Әгәр унны үстерерлек мөмкинлеге юк икән, ник шулхәтле үрчетергә тиеш әле ул? Күршеләре ярдәменә өмет итепме? Хезмәттәшләре булышыр дипме? Соң, «дәүләт ярдәме» дигәне дә шул ук күршеләр, хезмәттәшләр һ.б. авызыннан өзеп алынган өлеш бит инде аның. Бу яклап карасак, аларның бәхетле балачагын тәэмин итәрлек мөмкинлегең булмаган килеш бала табу – күпмедер дәрәҗәдә җавапсызлык булып чыга. Тамагының башкаларга салу дип әйтергә дә мөмкин. Туганнарыңамы, күршеләргәме, дәүләткәме – барыбер. Халыкта «юрганыңа карап аяк сузу» дигән әйтем бар. Әгәр кеше аягын юрганына карап сузмаган икән, күршеләре аңа үз юрганын бирергә тиешме?

Шул рәвешле, «күп балалы гаиләләргә ярдәмләшү» мәсьәләсен бер селтәнүдә хәл итеп булмый, моның универсаль ысуллары юк һәм һәр очрак аерым каралырга тиеш. Кемгә ярдәм итәләр?.. Кемнәр ярдәм итә?.. Һәм бу мәсьәлә кемнәрдәндер салым түләтү өчен нигез була алмый. Ләкин ул халыкны «баласызлар» һәм «күп балалылар»га бүлеп үзара дошманлаштыру өчен менә дигән сәбәп булырга мөмкин.

Гомумән, ни өчен дәүләт күп балалы гаиләләргә генә ярдәм итәргә тиеш әле? Һәрбер бала – кабатланмас, бердәнбер. Әллә алай түгелме? Күп балалы гаиләдә үскән кеше яхшырак, файдалырак, кадерлерәкме әллә? Ул – «беренче сортлы», ә ялгызы үскән бала «икенче сортлы» булып чыгамы? Күп балалыларга ярдәм итү сәясәте шуны раслый ич. Беркатлырак булганга микән, миңа гел сөекле дәүләтебез һәрбер бала турында тигез кайгыртырга тиештер кебек тоела.

Әлбәттә, әлеге тәкъдимне Россия депутатларының чираттагы сәерлеге дип тә карарга мөмкин булыр иде, ләкин алар соңгы елларда артык күбәеп китте. Шундый «тәкъдимнәр» күпме кешенең вакытын, энергиясен ала, ә кемнәрнеңдер сәламәтлеген дә какшата. Бәлки, дәүләт дәрәҗәсендәге шундый хәсрәт идеяләр тәкъдим иткән өчен берәр төрле җаваплылык (салым?) кертү турында уйларга кирәктер?

ЖӘЙ-2017

Качакларның балаларына юллама – бушлай

Казанда балаларның җәйге сәламәтләндерү лагерьлары 2 июньнән эшли башлый. Быел шәһәр яны лагерьлары 14847 баланы кабул итәчәк.

– Лагерьга 18 көнгә юлламаның тулы бәясе – 15 мең сум. Ата-аналар бу бәянең дүрт мең сумын гына түли. Балалар ялын оештыруга шәһәр бюджетыннан 210 миллион сумнан артык акча күчерелде, – диде шәһәр Башкарма комитетының балалар һәм яшьләр эшләре буенча комитеты рәисе Айрат Фәизов «эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә.

Башкалада муниципаль карамакта – 14 һәм предприятиеләр белән оешмаларның ун лагере исәпләнелә. Шәһәр яны лагерьларының матди-техник базасы быел да 14 миллион сумга яңартыла. «Березка» лагеренда республика программасы кысаларында, 11 миллион сумга 60 урынга исәпләнелгән ике яңа корпус төзелә.

– Төзекләндерү эшләре 25 майга йомгаклана. «Березка»да 2014 елны ашханәгә капиталь ремонт үткәрелгән иде инде, – диде Айрат Фәизов. – Лагерьларда медицина пунктлары эшләячәк.

Шәһәр яны лагерьларында ял итүче балаларда кәрәзле телефоннары үзләре белән була. Алар һәр очракта «ышаныч» телефоннарына **(8-800-200-122; 571-35-71)** шалтырата ала.

Мәктәп яны һәм шәһәр яны лагерьларыннан тыш, үсмерләр клублары базасында 32 мәйданчык булдырыла. Лагерьларга бармаган балалар өчен әлеге мәйданчыкларда төрле чаралар оештырылачак.

– Без лагерьларны саклап калдык. Качаклар белсен, аларның балаларына шәһәр яны лагерьларына юллама бушлай бирелә, – дип, мэр Илсур Метшин лагерьларда балаларның иминлеген тәэмин итәргә чакырды.

Шәһәр яны лагерьларына юлламалар 22 майдан бирелә башлый. Хәзер ата-аналардан гаризалар туплау бара. Юлламалар алу өчен «Ял» үзәгенә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Адресы: 25 Октябрь урамы, 13/б, тел. **590-24-82.** Сменалар турында мәгълүматны социаль челтәрләрдән дә алырга мөмкин **http://vk.com/yal kzn, www.instagram.com/mdu yal.**

Дамир БӘДРИЕВ.

Шушы көннәрдә Казанда «Россия төбәкләрендә этникара мөнәсәбәтләр гармониясендә милли-мәдәни автономияләрнең роле һәм урыны» дигән темага төбәкара конференция уза. Чарада илнең 40тан артык төбәгеннән килгән делегатлар катнаша. Алар арасында милли-мәдәни автономияләр җитәкчеләре дә, губернаторлар, вице-премьерлар, министрлар, ведомство җитәкчеләре дә бар. Татар федераль милли-мәдәни автономиясе оештырган конференциядә Кырым республикасы вәкилләре дә катнаша.

Казанда милли сәясәт мәсьәләләре карала

Россия Дәүләт Думасы депутаты Илдар Гыйльметдинов сүзләренчә, гадәттә, бездә иҗтимагый оешма вәкилләре – үзләренә аерым, башкарма структура вәкилләре үзләренә аерым эшли.

– Этникара мөнәсәбәтләр өлкәсендә аларның үзара бергәләшеп эшләве, тәҗрибә уртаклашуы мөһим. Чарада чит төбәкләрдән килүчеләргә Татарстандагы милли сәясәтнең ничек төзелүен дә күрсәтәсе, аның эш системасы белән таныштырасы килә. Әлеге үрнәкне алар да үзләрендә куллана алсын иде. Халыклар дуслыгы йортлары җитәкчеләре дә үзләре өчен яңа эш алымнары белән танышып китсә иде дибез. Шуның белән алар тагын да актив эшләп китәчәкләр. Бу өлкәдә проблемалар да юк түгел, конференция аларны хәл итү мәйданчыгы да булып тора. Милли-мәдәни автономияләр – дәүләт өчен гражданлык җәмгыяте белән аралашуда мөһим инструмент. Киләчәктә Халыклар дуслыгы йортларының бер ассоциациягә берләшү идеясе дә бар, – дип сөйләде ул «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында узган матбугат очрашуында.

Матбугат конференциясендә телләрне саклау мәсьәләсе дә күтәрелде. Спикерның сүзләренә караганда, балаларга телләрне мәктәптә генә түгел, балалар бакчасында ук өйрәтә башларга кирәк. Сабый вакытта телне үзләштерү сәләте көчлерәк.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.

Объективта – зур гаилә

Кичә – Халыкара гаилә көнендә – «Яңа Гасыр» телеканалы «В объективе ТНВ – большая семья» проектын башлап җибәрде. Аның төп бурычы – чын бәхетнең зур гаиләдә булуын күрсәтү, шулай ук татарстанлыларга тормыштагы иң төп кыйммәтләрне исләренә төшерү. Проект барышында зур һәм тату гаиләләргә багышлап тематик тапшырулар, нәфис һәм документаль фильмнар төшерү планлаштырыла.

Зөһрә САДЫЙКОВА

– Каналыбызның 15 еллыгын менә шундый зур проект белән билгеләп үтәсебез килде. Беренчедән, моның белән күп балалы гаиләләргә зур игътибар юнәлтәбез. Икенчедән, шушы өлкәдә дәүләт дәрәҗәсендә нинди законнар кабул ителгән һәм алар ничек эшли – шул хакта күбрәк күрсәтәчәкбез, – диде журналистлар белән очрашу вакытында «Татарстан – Яңа Гасыр» телеканалы җитәкчесе урынбасары Мәдинә Тимерҗанова.

Җитәкче әйтүенчә, «Яңа Гасыр» телеканалының тулы иҗади төркеме, иртәнге тапшырулардан башлап «Трибуна Нового Века – Трибуна депутата» һәм «Таяну ноктасы» программалары белән тәмамлап, татар һәм рус телләрендәге тапшыруларда зур гаилә төшенчәсенең мәгънәсен ачу өстендә эшләячәкләр. Роликлар «Бәхетемнең иң олысы» һәм «Счастье – в большинстве» шигарьләре белән тәмамлана. Проект исә үзе октябрь башында зур ток-шоу белән төгәлләнәчәк. Гомумән алганда, мондый тапшыруларда 18 гаилә катнашыр дип планлаштырыла. Алар арасында тугыз балалы гаиләдә тәрбияләнгән Татарстанның Беренче Президенты, Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев тә бар.

– Үз балалары бишәү булып, мөмкинлеге чикләнгән тагын дүрт баланы гаиләгә алган кешеләр – минем өчен Герой. Моның өчен зур йөрәкле булырга кирәк. Гомумән, һәр нормаль кешенең күңелендә күп балалы әти яки әни яшидер дип уйлыйм. Тормыш шартлары, һәртөрле мәшәкатьләр миңа да үз вакытында күп балалы әти булырга мөмкинлек бирмәде. Бәлки, шушы күп аспектлы социаль проект белән күңелнең бер почмагында «йоклаучы» күпбалалыкны уятырбыз, кешеләрнең тормышка карашларын бераз гына үзгәртә алырбыз. Әммә бар да ал да гөл дип күрсәтүне максат итеп куймыйбыз. Күпбалалы гаиләләрдә нинди проблемалар бар: социаль, финанс мәсьәләләре, медицина ярдәме күрсәтү, торак – барысын да күрсәтәчәкбез, – диде «Татарстан – Яңа Гасыр» телеканалы җитәкчесе Илшат Әминов.

Тапшырулардан тыш, әлеге проект барышында «Путешествие большой семьи. Выходной день с ТНВ» акциясе дә уздырыла. Ягъни күпбалалы гаилә бер көнне (шимбәне) «Яңа Гасыр» белән үткәрә: телеканал аларга республиканың төп туристлык маршруты буенча, шулай ук балаларның популяр күңел ачу урыннарына (аквапарк, зоопарк һәм башка кызыклы җирләргә) сәяхәт оештыра.

Моннан кала, «Счастье – в большинстве» темасына багышланган балалар бәйгесе уздырыла. Җиңүчеләрне тамашачылар телеканалның рәсми сайтында интерактив тавыш бирү юлы белән ачыклаячаклар. Иң яхшы өч эшнең авторы «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясеннән махсус бүләккә ия булачак.

Татарстанда 31 122 күп балалы гаилә исәпләнелә. Шуларның 18 217се – шәһәрдә, 12 905е авылларда яши.

Республикада 12 һәм 11 балалы – берешәр гаилә, ун балалы – биш гаилә һәм тугыз балалы – ун гаилә, ә өч балалы 27 431 гаилә бар.

«Авылда акча эшләп тә, рәхәтләнеп яшәп тә була»

Авыл «картая», яшьләр китә дип чаң сугабыз. Бүген авыл халкына нинди мөмкинлекләр бар соң? Салада төпләнәсе килгән яшьләргә эш, яшәү урыны бармы? 11-14 май көннәрендә «Яшьләр. Авыл. АПК» Халыкара авыл яшьләре форумы кысаларында, дөнья буйлап җыелган актив яшьләр әлеге сорауларга җавап табарга тырышты.

Алисә САБИРОВА

Бу авыр эштә аларга Татарстан җитәкчеләре, министрлар, район җитәкчеләре дә ярдәм итте. Республиканың премьер-министр урынбасары – Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов, авылларны саклау өчен дәүләт эшчәнлеген тамырдан үзгәртергә кирәк, ди.

– Син дә шәһәргә киттең, мин дә калада гомер итәм. Кем калсын соң авылда? Ә калдырырга тырышырга кирәк. Ул хакимият эше генә түгел. Ул – бөтен җәмгыять эше. Яшьләрне җәлеп итү өчен, авыл халкының тормыш дәрәҗәсе, хезмәт хакы шәһәрнекеннән ким булмаска тиеш. Безнең республика өчен авыл хуҗалыгы икътисад тармагы гына түгел, ул – яшәү рәвеше. Шуңа да «авыл картаюы» дигән тискәре процессны туктатырга кирәк. Республикада авыл яшьләре белән эшләүнең матур үрнәкләре бар. Узган елны Татарстанның Аграр яшьләр берлеге Питрәч районында «Скорлупино» дигән зур йомырка проектын тәкъдим итте. Бу үзенә күрә авыл тормышын саклап калу, аның фәлсәфи эчтәлеген күрсәтү чарасы, – диде Марат Әхмәтов.

Татарстанның яшьләр эшләре һәм спорт министры Владимир Леонов республиканың авыл яшьләре белән системалы эш алып барылуына басым ясады.

– 2011 елдан бездә «Татарстан Республикасының авыл яшьләре 2014-2020» дигән аерым программа эшли. Форум кысаларында, без төбәкләрдә булган иң алдынгы тәҗрибәләр белән уртаклаша алырбыз дип өметләнәм, – диде Владимир Леонов.

Форумга 18-35 яшьлек авыл яшьләре җыелды. Араларында Германия белән Белоруссия вәкилләре дә бар иде. Белоруссия кунагы Макей Франц соңгы вакытта яшьләрнең фермерлык эшенә һәм авыл туризмына тартылуын билгеләп китте.

–Яшьләр хәзер үз фермаларын булдырырга тырыша. Дөрес, кемдер бу эшне башлап ташлый. Аларның тискәре тәҗрибәсе башкаларда да җир эшенә курку уята. Безнең максат – «авылда эшләве авыр» дигән төшенчәне юк итү. Авылда акча эшләп тә, рәхәтләнеп яшәп тә була. Бу – форумның максат-бурычлары белән дә тәңгәл килә, – ди Макей.

Һәр район яшьләрне үзенчә җәлеп итәргә тырыша. Әйтик, Мөслим районы җитәкчесе эш урыннарына яшь белгечләрне утыртырга тырыша икән. Эш кенә түгел, ялга да вакыт таба мөслимлеләр. Район үзәгендә Зур спорт комплексы төзелә, узган ел матур яр буе ясап куйганнар. «Курай», «Пушкин» парклары ачылган. Тулы бәхет өчен районның үз бала тудыру йорты гына юк. Аны район хастаханәсен ремонтлаганнан соң ябып куйганнар.

– Бездә фермерлык бик көчле. 26-35 яшьлекләр икешәр ферма тота. Мөгезле эре терлек, кош-корттан тыш, күпләп куяннар да асрый башладылар. Үз кибетләрен ачкан яшьләр дә бар. Яшьләребез төрле интеллектуаль ярышларда катнаша. Әле күптән түгел «Мөслим даһилары» уенын үткәрдек. Бәйгедә җиңгән өч команданы Зөя шәһәренә сәяхәткә алып барачакбыз, – ди «Аграр яшьләр берләшмәсе»нең Мөслим бүлеге рәисе Лилия Морзаханова.

Татарстанның үз Аграр яшьләр берлеге бар. Ул инде җиденче ел актив эшләп килә. Үзәкләре Казанда булса да, аларның районнардан кайтып кергәне юк. Төрле чаралар, фестивальләр үткәреп йөриләр. Быел, мәсәлән, алар Зәй районында «SunnyФест», ә Әгерҗе районында «Пчелино» фестивальләре оештыралар. Берлек рәисе Миләүшә Заһидуллина белдерүенчә, бу чаралар, бер яктан, яшьләрне кызыксындырса, икенче яктан, туристларны җәлеп итү чарасы. Димәк, районның социаль-икътисади хәле дә үзгәрә.

– Дөрес, форумда күтәрелгән проблемалар иртәгә үк тормышка ашмаячак. Без авыл яшьләренә тормышта үзләрен табарга ярдәм итәбез. Балыкчыга кармак тоттырган кебек, аларга эшләргә мөмкинлек бирәбез. Ә нинди балык тотулары аларның үзеннән тора инде. Авылга мәхәббәт бер көндә генә тәрбияләнә торган эш түгел. Шуңа да балалар белән төрле чаралар үткәрәбез. Моннан җиде ел элек яшьләр үзләренә туры килгән программалар, «подъемный»лар турында да берни белми иде. Хәзер хәл уңай якка үзгәрде, – ди Миләүшә Заһидуллина.

Берлек рәисе сүзләренчә, хәзер яшьләр дә максатчан рәвештә авылга кайта. Аларны җәлеп итү инде проблема түгел. Көн кадагында – яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү. Берлек шул проблеманы хәл итә.

Форум барышында Татарстанның Аграр яшьләр берлеге белән Россия авыл яшьләре берләшмәсе арасында икеяклы килешү төзелде. Миләүшә Заһидуллина сүзләренчә, бу – төбәкләр арасында тәҗрибә уртаклашу өчен зур мөмкинлек булачак.

–Элек без Россия авыл яшьләре берләшмәсе белән уртак тел таба алмый идек. Алар интернет кертү кебек вак мәсьәләләргә туктала иде. Татарстан авыллары өчен бу күптәннән инде проблема түгел. Без бер урында җыела алмасак, тиз генә интернет аша элемтәгә керәбез. Республика җитәкчеләре авылларга, авыл яшьләренә аерууча да игътибарлы. Ләкин әле күп төбәкләр бу игътибардан мәхрүм. Килешү бер-беребезгә тәҗрибә уртаклашу, бергәләп үсеш мөмкинлеге бирәчәк, – диде Миләүшә Заһидуллина.

СӘНГАТЬ ӘХРАМЫ

Табигать – иң маһир иҗатчы

Искәргәнегез бардыр, кыргый табигатьне төшерүче фотографларның эшләре хәтта ки башка темаларны яктыртучы бик мәшһүр профессионаллар җирлегендә дә аерылып торучан. Алар төшергән сурәтләр ниндидер вакыйганы гына чагылдырып калмый, ә үзенә күрә бер кыйссаны, тормыш фәлсәфәсен бәян итә кебек. Андый фотосунарчылар, дөресен генә әйткәндә, дөньяга битараф булмаганнарның игътибарын җәлеп итүдән тыш, гап-гади кешеләрнең дә табигать могҗизаларына күзләрен ачып, әйләнә-тирә мохит белән аралашу теләге уята.

Расиха ФӘИЗОВА

Олпат язучы Марсель Галиевнең «Шәһри Казан» редакциясенең күргәзмәләр залында ачылган 50 эшне берләштергән «Тынлык дәшкәндә» дип аталган күргәзмәсе нәкъ менә шушы максатны күздә тота кебек. Аның пеләш башлы гап-гади гөмбәләре дә бәбәкләрен сиңа төбәп карап торган ниндидер экзотик, күз күрмәгән илаһи бер зат кебек кабул ителә. Менә шулай һәр эше белән ул табигатьнең бик тә маһир иҗатчы булуын тәкрарлый бара. Бирсдә автор, чыннан да шулаймы соң бу, кебек икеле-микеле уйларга урын калдырмый. Барысы да ничек бар шулай, анадан тума, кем әйтмешли. Әнә тере агач кәүсәсендә тымызык кояш җылысын тансыклап черем итәргә дип йомгактай йомарланып яткан «Каен таҗы» да, үткән-сүткәнне бертотам калмый күзәтеп торучы «Остаз» да, петуния таҗына «кунаклаган» «Галәм хуҗасы» да ничек бар, шул кимәлдә тотып алынган. Кар астыннан тырпаеп утырган куралары да ниндидер затлы, әрфиядәй кышкы чәчәкне хәтерләтә. Ак кардагы ак чәчәкнең дә үз төсмере, үз холкы бар. Монда, билгеле, кайсы маркадагы, нинди мөмкинлекләре булган фотоаппарат булуда түгел хикмәт. Иң беренче чиратта аның кем кулына килеп эләгүе мөһим. Бары тик сизгер күңелең белән шуларны күрә һәм күрсәтә генә бел. Шул рәвешле, моңа кадәр хәтта ки күзгә-башка күренмәгән җилне дә («Чатыртау җиле») башкалар күрерлек, истә калдырырлык итеп тасвирлый белгән; кемдер тәгаен генә тәрҗемәсен таба алмый зар-интизар килгән бер заманда, «моң», «татар моңы»на сүздән «үз милизмнарын» өстәүче әдипнең сүз сурәтеннән күз сурәтенә күчү мәле бу. Искитмәле мөкәммәл эшләр! Шулар өстенә рәссам да бит әле үзе. Урманнарның бар булмышын, кыргый матурлыгын, кабатланмас хозурлыгын җете дә, кызык та итеп, үз фәлсәфәсенә төреп бирә белүе дә шуннан, күрәсең. Казан тирәсендәге урманнарда югарыдан шундый әзер сәнгать әсәрләре индерелгән дип кем уйлаган?! Кайбер фото осталары кайвакыт чынбарлыктан качу өчен еш кына мөрәҗәгать итә торган томан, чагылу (әйтик, суда) кебек ярдәмчел эффектлар да юк биредә. Шуңа да карамастан, һәр кадрның табыш булуы бәхәссез. Әнә 90нчы елларда матбугат һәм мәгълүмат министры һәм озак еллар буе «Идел-пресс» полиграфия-нәшрият комплексының генераль директоры булып эшләгән Ислам ага Әхмәтҗанов та:

– Без Марсель туганны коеп куйган шагыйрь, менә дигән прозаик, нәзберек юмор остасы дип кенә белә идек. Юкса без дә шушы дөньяда, шушы урманнардан йөрибез бит, нигә болар бер дә безнең күзгә чалынмады икән дә, нигә без аны күрмәдек икән?! – дип гаҗәпләнә.

Әлбәттә, моның өчен күңел күзең булу кирәк. Күргәзмә ачылышына килгән олпат язучы Рабит ага Батулла да шул фикердә.

– Күңел күзе теләсә кемгә бирелми. Ул нәселдән, табигатьтән килә. Ходам сакласын күңел күзе сукыр булганнардан. Сәнгать белән җитәкчелек иткән кешеләрнең күзе сукыр булса, бетте… Ә табигатьнең үзендә бөтен нәрсә бар, безгә шуны күрә белергә генә кирәк, – ди ул.

Күрергә кирәк шул. Аннан нәрсә күрүебез, аңа ничек каравыбыздан да тора бит әле. Мөнәсәбәттән дә. Дөрес, фотога төшерим дигән һәр кешенең кулында фотоаппарат, селфи таягы бүген (кызык, ә бит 1995 елда гына әлеге таяк «Файдасы булмаган уйлап табу»лар исемлегенә кертелгән булган). Марсель Галиев тә әллә нинди катлы-катлы объективлары булган фотоаппарат белән йөрми – күзенә берәр матур әйбер чалына калса, кесәсендә йөргән телефон фотоаппаратына төшерә икән. Ә инде фото эше белән бер бүген генә кызыксынуы түгел авторның. Бу мавыгу, кызыксыну балачактан ук килә, ди. 7нче класста укыганда, элеккеге ярлы чорда, үзе әйтмешли, Советлар Союзында танклар һәм пушкалар гына ясый торган заманда фото эшенә өйрәткәннәр аларны мәктәптә.

– Ул вакытта юк иде фотоаппарат. Әлбәттә, ала алмадык без аны. Ә кызыксыну калды. Аннан соң әллә ничә фотоаппарат алынды инде. Минем пейзажлар да, шәхесләрнең портретлары да бар. Ләкин андыйны хәзер күп кеше төшерә. Ә менә табигатьнең кайбер күренешләрен гомумиләштерү, шуннан фәлсәфә чыгара алу ул – сирәк күренеш дип саныйм. Мин урманда йөрергә яратам, шунда күреп алам инде боларны ничектер. Мисал өчен әнә агач кәүсәсендәге кеше сурәтен алыйк («Яугир. Хуннар сугышчысы»). Шуның янынннан киттем үтеп һәм нигәдер имәнеп туктап калдым. Кеше йөзе чалынып киткән кебек, чакырадыр кебек тоелды. Борылып килсәм, каршымда, чыннан да, агачның кәүсәсендә кеше сурәте тора. Хәзер инде алар белә үзләре белән кызыксынганны, шуңа күрә кайберләре әнә шулай үзе «дәшеп китерә», – дип елмая әдип.

Һәм, әлбәттә, яңа сезонны башлап, янә таныш сукмаклардан кабат-кабат үтәргә, үзенең урман «иярәрен» барлап чыгарга аның нияте.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Газинур МОРАТ,
язучы:

– Марсель Галиевнең менә тагын бер хикмәте ачылды. Моны да шул әдәби иҗатының үзенә күрә дәвамы, югары дәрәҗәдәге шигърият дип исәплим. Ул бит шуның өстенә шәп рәссам да. Аның югары һөнәри дәрәҗәдә карандаш белән иҗат ителгән эшләре бар. Әгәр дә ул язучы булмаса, һичшиксез, рәссам булып киткән булыр иде.

Розалина ШАҺИЕВА,
сәнгать белгече:

– Бу күргәзмә безнең сынлы сәнгатьтә яңа бер сәхифә ачачак. Мин моңа чын мәгънәсендә ышанам. Чөнки ачыш бу. Табигатнең шундый самими, ихластан илаһи иҗаты – әверелүләр темасы. Марсель Галиев чын мәгънәсендә ниндидер яңарыш чоры тудырды. Бу әйберләрнең дә киләчәге зур.

Халисә ИСМӘГЫЙЛЕВА,
режиссер, «Казан» милли мәдәният үзәге директоры урынбасары, «Азнакай» якташлар җәмгыяте рәисе:

– Якташым Марсельнең иҗатына еллар дәвамында мөкиббән китеп, горурланып, аны һәрвакыт тамашачы хозурына җиткерә киләм. Әле күптән түгел генә үзебездә, зурлап, иҗат кичәсен уздырдык. Аның зур талант иясе икәнен моңа кадәр дә белә идек, әмма бу кадәр үк дип белмәгәнбез. Булганнан бар да була шул. Афәрин!

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА,
язучы:

– Без дә күрәбездер кайбер гайре табигый әверелешләрне, ләкин ничектер туктап, аңа мәгънә биреп шуларны төшереп алу һәркемнең хәленнән килми. Монда Марсель абыйның тарихка мөкиббән китүен, тарихны белүен дә искә алган хәлдә, әллә нинди чорларга кереп китәсең.

Фәндәс САФИУЛЛИН,
сәясәтче:

– Мин үзем дә фотограф. Минеке-ннән яхшырак түгел микән дип – иң беренче күзәтүем шул булды. Минем фотолардан тирәнрәк. Бу – җан, күңел белән тоя торган сәнгать, философ-фотографның иҗаты. Аның төп мәгънәсен мин шулай аңладым: табигатьнең җаны да, күренеше дә, күрә белсәң, кеше җаныннан, кеше табигатеннән аерылмый. Табигать дөньясының, кешелек дөньясының бер икәнлеге күрсәтелгән. Кешенең табигатьне үзенеке итеп күрә белүе борынгыдан – мәҗүсилектән калган хисләр. Менә шул тойгылар яңарган монда. Болай гына узып киткәндә, күзең 100 процент сәламәт булса да, күрми торган нәрсәләрне күрә белгән. Бизрәк тә шул фәлсәфи, рухи ягын. Әдәбиятта иҗат кешесе язучымы, шагыйрьме ул, философ булганда гына иң тирән язучы була, һәм язучы булганда гына, иң тирән философ була. Марсельнең язмышында менә шул бәхет бар.

Тизлекне арттыру – үлемгә якынаю

Берләшкән Милләтләр Оешмасы башлангычында дүртенче Глобаль атна пропаганда чарасы уткәрелде.Быел игътибар юлларда тизлек таләпләрен саклауга юнәлтелде.

Дамир БӘДРИЕВ

ХӘРӘКӘТ ИМИНЛЕГЕ

Автор фотосы

Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы мәгълүматларына караганда, сәгатенә 50 километр тизлектә килгән автомобиль кешене бәрдерсә, бу һәлакәттә җәяүленең үлү ихтималы 20 проценттан азрак. Әгәр инде тизлек сәгатенә 80 километр булса, бәрдерелгән җәяүленең үлү ихтималы 60 процентны тәшкил итә.

Казанда быелның дүрт аенда тизлек таләпләрен сакламау сәбәпле, 140 юл-транспорт һәлакәте килеп чыкты. Ахыры аянычлы – өч кешенең гомере өзелде, 164 кеше төрле авырлыкта имгәнү алды.

– Киров районында быел биш баланы машина бәрдерде. Бәхеткә, үлүчеләр юк. Ләкин юл-транспорт һәлакәтенә эләккән бала психологик травмадан бик озак арына. Бала тотлыга торган булып та, урамнан курка торган булып та калырга мөмкин. Шунлыктан без, райондагы мәктәпләр һәм балалар бакчалары укытучы-тәрбиячеләре белән берлектә, балаларга юл хәрәкәте кагыйдәләрен ныклап өйрәтергә тырышабыз. «Юл хәрәкәте яшь инспекторлары» түгәрәкләренә йөрүче актив малайлар һәм кызлар инде үзләре чын пропагандистларга әвереләләр, – ди башкаланың Киров районы буенча ЮХИДИ бүлекчәсе автоинспекторы Илназ Шакирҗанов.

Киров районындагы 135нче мәктәп укытучысы Динара Забегаева җитәкчелегендәге яшь инспекторлар гаҗәеп бөтерчекләр икән. Дүртенче сыйныфта гына булсалар да, мәктәптәге чараларда да катнашалар, урамда җәяүлеләрне дә юл хәрәкәтендә игътибарлы булырга өндәргә җитешәләр. Тизлек таләпләрен сакларга чакырган плакатлар тотып, үзенчәлекле акция дә уткәрделәр әле. Автоинспектор Илназ Шакирҗанов искәрткәнчә, Декабристлар урамындагы 125 а йортында урнашкан 1нче шәһәр балалар хастаханәсе бүлекчәсе янында юл бик хәвефле.

– Хастаханә янында автомобильләр куеп тору урыны кечкенә. Кешеләр машиналарын юл читендә калдырырга мәҗбүр. Транспорт чараларын идарә итүчеләрнең кайберләре, Ленская урамы юлынаан килгәндә, тизлек таләпләрен сакламый. Балаларын күтәреп яки җитәкләп хастаханәгә керүче-чыгучы кешеләрнең машина астында калулары ихтимал, – ди Илназ Шакирҗанов.

Плакатларның берсенә «Сезне өйдә көтәләр!» дип язылган иде. Транспорт чараларын идарә итүчеләр дә, җәяүлеләр дә, юл хәрәкәте кагыйдәләрен төгәл үтик, үзара игътибарлы булыйк. Барыбызның да өйгә исән-сау кайтуын көтәләр бит.

ИГЪТИБАР

Барыбыз да күз-колак булыйк

2017 елның июнь аенда шәһәребездә FIFA Конфедерация Кубогы уеннары узачак. Бик күп катнашучылар, тамашачылар, туристлар килүе көтелә. Спорт бәйрәме алдыннан һәм уеннар вакытында куркынычсызлыкны тәэмин итү өчен Татарстанның хокук саклау органнары гражданнарга түбәндәге затларга игътибарлы булуны сорый:

– спорт корылмалары, транспорт объектлары һәм шулай ук чемпионатны оештыручы һәм анда катнашучылар белән нигезсез кызыксынучылар;

– химик реактивлар, агулар һәм террорлык актында файдаланырдай матдәләр белән кызыксынучылар;

– кулындагы сумкаларын спорт корылмаларына һәм башка объектларга алып керешергә яки төрле сәбәпләр табып әйберләрен саклап торуны үтенүчеләр;

– кыска вакытка торак арендалаучылар;

– кеше күп урыннарда һава торышына карап киенмәүчеләр.

Шулай ук хуҗасыз калган әйберләргә, предметларга игътибарлы булу һәм бу хакта ашыгыч рәвештә хокук саклау органнарына хәбәр итү сорала.

Гражданнар мәгълүматны аноним төстә дә җиткерә ала. Эчке эшләр министрлыгына һәм Россия Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан буенча идарәсенә шалтыратырга кирәк.

Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы: **291-35-28, 291-23-40, 291-24-40, 291-20-02.**

Россия Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе: **231-45-55.**

Россия Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе купканаллы телефоны: **231-49-00.**

КЕШЕ ҺӘМ ХОКУК

Өйгә кермә – атам!

Америка Кушма Штатларында шәхси территориягә кергән җинаятьчене милек хуҗасы шунда ук атып үтерергә мөмкин. Һөҗүмгә дучар булган америкалылар, чакырылмаган «кунак»ны үтергән очракта, үзләренең гаепле түгеллекләрен дәлилләү җаваплылыгыннан да азат.

Рәдиф КАРАГАЙ

Шушы хәлләрнең, озакламыйча, безнең яшәешебездә дә күзәтелә башлавы ихтимал. Россия Дәүләт Думасы депутатлары гражданнарның үз йортларын саклаганда саклану хокукларын киңәйтү турында закон проекты әзерли. Җинаять кодексының 37нче маддәсенә үзгәреш кертү ниятләнелә. Кеше һөҗүм итүче җинаятьчегә төрле авырлыктагы имгәтү ясаса, бу «җинаять» саналмаячак. Әгәр җинаятьче законлы милек чикләренә яки бинага (йорт, фатир, дача, офис) рөхсәтсез рәвештә үтеп керсә, фатирда яки шәхси йортта көчсез хәлдәге башка кешеләрне яклап, җинаятьче һөҗүмен кире кайтару да «саклану вәкаләтләрен арттырып җибәрү» дип бәяләнмәячәк. Урамда саклану вәкаләтләрен арттырып җибәрергә ярамый.

Закон проекты авторлары фикеренчә, россиялеләр үзләрен һәм шәхси йортларын, шулай ук туганнарын яклаудан курыкмаска тиеш. Үзеңне яклауга тулы хокук булырга тиеш. Хәтта гражданнар коралын (травматика) кулланып та. Закон проектын әзерләүдә катнашучы Россия Эчке эшләр министрлыгы һәм Росгвардия экспертлары шәхси йортларны биек коймалар белән уратып алырга, капка-ишекләрне бикле тотарга, «сигнал» куярга тәкъдим итә. Бакча (дача) йортларында сукмакка шартлаткычлар куму, узеннән-үзе ата торган гарпун-сөңгеләр көйләү, ашамлыкларны агулап калдыру тыела. Карак, кимендә, өч елга төрмәгә эләгәчәк. Дача хуҗасы, кеше үтерергә алдан ук әзерләнгән дип бәяләнеп, тагын да күбрәк вакытка ирегеннән мәхрүм ителәчәк.

Росгвардия мәгълүматларына караганда, Россиядә гражданнарда законлы рәвештә 909 мең травматик пистолет, шома көпшәле – 4,4 миллион һәм сырлы көпшәле 886 мең мылтык исәпләнә. Закон кабул ителгәч, шушы арсенал «ут чәчә» башламасмы?

Дәүләт Думасында бу закон проекты гади халыкны түгел, ә замана байларын кайгыртып әзерләнелә кебек.

Рафил НОГМАНОВ,
Татарстан Республикасы Дәүләт Советының законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе урынбасары:

– Россия Федерациясе Дәүләт Думасында гражданнарның үз йортларын саклауда саклану хокукларын киңәйтү турында әзерләнелә торган закон проекты күңелемдә зур шикшөбһәләр тудыра. Без килачәктә күршеләребезне ата башламагаек дип борчылам. Җинаятьче һөҗүм итсә, әлбәттә, төрле мөмкинлекләр белән сакланасың. Йортың капкасына яки ишегеңә исерек шакый ди. Аны атып үтерергәме инде? Исерек кайсы ишеккә шакыганын үзе дә аңларлык халәттә булмый кайчак. Мондый закон кабул ителсә, трагедияләр кискен артыр дип шикләнәм. Безгә бөтен нәрсәдә дә АКШ артыннан иярергә кирәкмидер. Әлеге закон проекты мәсьәләсендә бик җитди уйлану зарур.

«Barudi»га син дә кушыл

26 майда Татар теле һәм әдәбияты буенча «Barudi» II Бөтендөнья онлайн контроль эше узачак.

Ни өчен Барудимы? Чөнки Татарстан Диния нәзарәте тарафыннан 2017 ел – Галимҗан Баруди елы дип игълан ителде. Быел Россиянең бөек дин галиме, дин һәм җәмәгать эшлеклесе, педагог, мөфти Галимҗан Барудиның тууына 160 ел тула. Шул уңайдан КФУның мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати системалар югары мәктәбе һәм Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара коммуникацияләр институты, татар мәдәниятен популярлаштыру һәм Барудиның мирасын өйрәнү максатында, кабат халыкара проект башлый.

Татарлар эз басмаган җир юктыр да, мөгаен. Халкыбыз дөнья буйлап сибелеп яши. Россиянең Идел, Урал буенда, Себердә, Казахстанда, Урта Азиядә, Ерак Көнчыгышта барлыгы 6 млн га якын татар кешесе яши, ә бөтен дөнья буйлап исәпләгәндә – 8 млн. Татар теле – элеккечә үк, төрки телләр арасында иң күп таралган телләрнең берсе. Узган ел Татар теле һәм әдәбияты буенча «И туган тел, и матур тел» I Бөтендөнья онлайн контроль эшендә 10 меңнән артык кеше катнашты. Тестның географиясе – Казан, Түбән Кама, Чаллы, Алабуга, Яшел Үзән, Әлмәт һәм республиканың башка шәһәрләре иде. Проектка Мәскәү, Уфа, Санкт-Петербург та кушылды. Шул ук вакытта дөньяның Токио, Цукубе (Япония), Хельсинки (Финляндия), Сан-Франциско (АКШ), Торонто (Канада), Сакарьедагы (Төркия) татар диаспорасы да күтәреп алды.

Республиканың кайбер мәктәпләрендә класслары белән татар телен ничек белүләрен тикшереп караучылар да табылды. Проектта катнашучылар арасында Татарстан Республикасының юстиция министры Лариса Глухова, «Таттелеком»ның генераль директоры Лотфулла Шәфыйгуллин, Бөтендөнья татар яшьләре форумы рәисе Тәбрис Яруллин кебек билгеле кешеләр дә бар иде.

«Barudi» проекты Галимҗан Барудиның тормышыннан тарихи фактларга нигезләнә. Проект бернинди коммерцияне, табыш алуны, ә биремнәр билге куюны күздә тотмый.

Контроль эш берничә этапны үз эченә ала:

1. Татар телен белүгә бирем –Галимҗан Баруди турындагы текстның кушымчалары төшереп калдырылган.

2. Галимҗан Баруди тормышындагы фактларны эченә алган текст.

3. Өйрәнү-танып белү өчен бонус-тур – «Галимҗан Барудиның тормыш картасы».

Беренче һәм икенче этапта сорауларга җавапларны бер сәгать эчендә бирергә кирәк. Өченчесе өстәмә этап булып тора һәм ул берничек тә бәяләнмәячәк. Контроль эшкә старт Мәскәү вакыты белән 00:00 сәгатьтә биреләчәк. Сайтта теркәлгән файдаланучылар өчен контроль эш тәүлек дәвамында ачык булачак. Контроль эшне уздыру вакыты барлык вакыт поясларын исәпкә алып сайланган. Проектның рәсми сайтында – http://tattest.ru/ алдан ук онлайн-теркәлү узарга мөмкин. Контроль эш нәтиҗәләре буенча электрон сертификатлар биреләчәк.

Кириллицадан тыш, татарчаның латин версиясе дә бар. Чөнки Төркия, Финляндия, Чехия, Польша, АКШ, Австралия һәм башка илләрдә яшәүче татарлар хәзер дә татарчаны латин хәрефләре белән яза. «Barudi» проектында теләге булган һәркем, хәтта ки татар телен, тарихын бик үк тирән белмәүчеләр дә катнаша ала.

Шулай ук оештыручылар 26 май көнне 12.00 сәгатьтә КФУда (Кремль урамы, 108нче аудитория, 1нче кат) узачак очрашу вакытында онлайн тест узарга чакыра. Очрашуга килүчеләр укырга керү, факультетларда уку һәм «Barudi» проектының ничек барлыкка килүе хакында тулырак мәгълүмат белә алачак.

БАЛАНС ГОСУДАРСТВЕННОГО (МУНИЦИПАЛЬНОГО) УЧРЕЖДЕНИЯ

на 1 января 2017 г.

	Форма по ОКУД	0503730
	Дата	01.01.2017
Наименование учреждения: МОУ «Средняя общеобразовательная школа №18 с углубленным изучением английского языка» Вахитовского р-на г.Казани	по ОКПО	1655033383
Периодичность: годовая		
Единица измерения: руб	по ОКЕИ	383

АКТИВ	Код строки	На начало года: деятельность с целевыми средствами	На начало года: деятельность по государственному заданию	На начало года: приносящая доход деятельность	На начало года: итого	На конец отчетного периода: деятельность с целевыми средствами	На конец отчетного периода: деятельность по государственному заданию	На конец отчетного периода: приносящая доход деятельность	На конец отчетного периода: итого
1	2	3	4	5	6	7	8	9	10
I. Нефинансовые активы Основные средства (балансовая стоимость, 010100000), всего*	010	-	42 415 371,34	306 933,00	42 722 304,34	-	43 829 612,49	306 933,00	44 136 545,49
недвижимое имущество учреждения (010110000)*	011	-	35 486 499,92	-	35 486 499,92	-	35 486 499,92	-	35 486 499,92
особо ценное движимое имущество учреждения (010120000)*	012	-	5 642 327,77	306 933,00	5 949 260,77	-	7 056 568,92	306 933,00	7 363 501,92
иное движимое имущество учреждения (010130000)*	013	-	1 286 543,65	-	1 286 543,65	-	1 286 543,65	-	1 286 543,65
предметы лизинга (010140000)*	014	-	-	-	-	-	-	-	-
Амортизация основных средств*	020	-	34 553 213,99	216 733,00	34 769 946,99	-	35 625 515,05	216 733,00	35 842 248,05
в том числе: Амортизация недвижимого имущества учреждения (010410000)	021	-	28 161 289,22	-	28 161 289,22	-	28 161 289,22	-	28 161 289,22
Амортизация особо ценного движимого имущества учреждения (010420000)*	022	-	5 242 794,47	216 733,00	5 459 527,47	-	6 293 218,11	216 733,00	6 509 951,11
Амортизация иного движимого имущества учреждения (010430000)*	023	-	1 149 130,30	-	1 149 130,30	-	1 171 007,72	-	1 171 007,72
Амортизация предметов лизинга (010440000)*	024	-	-	-	-	-	-	-	-
Основные средства (остаточная стоимость, стр.010-стр.020)	030	-	7 862 157,35	90 200,00	7 952 357,35	-	8 204 097,44	90 200,00	8 294 297,44
из них: недвижимое имущество учреждения (остаточная стоимость,стр.011-стр.021)	031	-	7 325 210,70	-	7 325 210,70	-	7 325 210,70	-	7 325 210,70
особо ценное движимое имущество учреждения (остаточная стоимость, стр.012-стр.022)	032	-	399 533,30	90 200,00	489 733,30	-	763 350,81	90 200,00	853 550,81
иное движимое имущество учреждения (остаточная стоимость, стр.013-стр.023)	033	-	137 413,35	-	137 413,35	-	115 535,93	-	115 535,93
предметы лизинга (остаточная стоимость, стр.014-стр.024)	034	-	-	-	-	-	-	-	-

Форма 0503730 с. 2

АКТИВ	Код строки	На начало года: деятельность с целевыми средствами	На начало года: деятельность по государственному заданию	На начало года: приносящая доход деятельность	На начало года: итого	На конец отчетного периода: деятельность с целевыми средствами	На конец отчетного периода: деятельность по государственному заданию	На конец отчетного периода: приносящая доход деятельность	На конец отчетного периода: итого
1	2	3	4	5	6	7	8	9	10
Непроизведенные активы (балансовая стоимость, 010300000)	070	-	81 383 496,48	-	81 383 496,48	-	81 383 496,48	-	81 383 496,48
Материальные запасы (010500000)	080	-	51 572,00	4 005,01	55 577,01	-	111 907,83	115 230,91	227 138,74
Итого по разделу I (стр.030 + стр.060 + стр.070 + стр.080 + стр.090 + стр.100 + стр. 140)	150	-	89 297 225,83	94 205,01	89 391 430,84	-	89 699 501,75	205 430,91	89 904 932,66
II. Финансовые активы Денежные средства учреждения (020100000)	170	-	45 744,73	498 474,29	544 219,02	2 360,57	26 356,00	898 070,26	926 786,83
в том числе: денежные средства учреждения на лицевых счетах в органе казначейства (020111000)	171	-	45 744,73	498 474,29	544 219,02	2 360,57	26 356,00	898 070,26	926 786,83
Расчеты по выданным авансам (020600000)	260	-	267 112,95	-	267 112,95	-	-	-	-
Прочие расчеты с дебиторами (021000000)	330	-	-89 108 240,48	-90 200,00	-89 198 440,48	-	-89 472 057,99	-90 200,00	-89 562 257,99
расчеты с учредителем (021006000)*	336	x	-122 512 324,17	-306 933,00	-122 819 257,17	x	-123 926 565,32	-306 933,00	-124 233 498,32
амортизация особо ценного движимого, недвижимого имущества*	337	x	33 404 083,69	216 733,00	33 620 816,69	x	34 454 507,33	216 733,00	34 671 240,33
Остаточная стоимость особо ценного движимого, недвижимого имущества (стр. 336+стр.337)	338	x	-89 108 240,48	-90 200,00	-89 198 440,48	x	-89 472 057,99	-90 200,00	-89 562 257,99
Итого по разделу II (стр.170 + стр.210 + стр.230 + стр.260 + стр.290 + стр.310 + стр.320 + стр. 335 + стр.370 + стр.380)	400	-	-88 795 382,80	408 274,29	-88 387 108,51	2 360,57	-89 445 701,99	807 870,26	-88 635 471,16
БАЛАНС (стр.150 + стр. 400)	410	-	501 843,03	502 479,30	1 004 322,33	2 360,57	253 799,76	1 013 301,17	1 269 461,50

Форма 0503730 с.5

Расчеты по доходам (020500000)	580	-	-	-	-	2 360,57	-	-	2 360,57
Расчеты по ущербу и иным доходам (020900000)	590	-	-	-	-	-	-	-	-
Итого по разделу III (стр.470+ стр.490 + стр. 510 + стр.530 + стр.570 + стр.580 + стр.590)	600	-	-	-	-	2 360,57	-	-	2 360,57
IV. Финансовый результат финансовый результат экономического субъекта(040100000) (стр. 623+стр.623^1 стр.+624+стр.625+стр.626)	620	-	501 843,03	502 479,30	1 004 322,33	-	253 799,76	1 013 301,17	1 267 100,93
финансовый результат прошлых отчетных периодов (040130000)	623	x	-32 902 240,66	285 746,30	-32 616 494,36	x	-34 200 707,57	796 568,17	-33 404 139,40
финансовый результат по начисленной амортизации по ОЦИ	623^1	x	33 404 083,69	216 733,00	33 620 816,69	x	34 454 507,33	216 733,00	34 671 240,33
БАЛАНС (стр.600 + стр. 620)	900	-	501 843,03	502 479,30	1 004 322,33	2 360,57	253 799,76	1 013 301,17	1 269 461,50

<*> Данные по этим строкам в валюту баланса не входят. Директор МАОУ «Школа №18 Шевелева Н.М

Учреждение: МОУ «Средняя общеобразовательная школа №18 с углубленным изучением английского языка» Вахитовского р-на г.Казани	по ОКПО	1655033383
Периодичность: годовая		
Единица измерения: руб	по ОКЕИ	383

Наименование показателя	Код строки	Код аналитики	Деятельность с целевыми средствами	Деятельность по государственному заданию	Приносящая доход деятельность	Итого
1	2	3	4	5	6	7
Доходы (стр.030 + стр.040 + стр.050 + стр.060 + стр.090 + стр.100 + стр.110)	010	100	1 777 983,46	41 049 860,37	4 329 280,98	47 157 124,81
Доходы от собственности	030	120	-	-	-	-
Доходы от оказания платных услуг (работ)	040	130	-	41 090 286,92	4 231 880,98	45 322 167,90
Доходы от операций с активами	090	170	-	-1 414 241,15	-	-1 414 241,15
доходы от реализации активов	092	172	-	-1 414 241,15	-	-1 414 241,15
доходы от реализации нефинансовых активов	093	172	-	-1 414 241,15	-	-1 414 241,15
Прочие доходы	100	180	1 777 983,46	1 373 814,60	97 400,00	3 249 198,06
в том числе: субсидии	101	180	1 777 983,46	-	-	1 777 983,46
иные прочие доходы	104	180	-	1 373 814,60	97 400,00	1 471 214,60
Расходы(стр.160 + стр.170 + стр. 190 + стр.210 + стр. 230 + стр. 240 + стр. 250 + стр. 260 + стр. 290)	150	200	1 777 983,46	42 348 327,28	3 818 459,11	47 944 769,85
Оплата труда и начисления на выплаты по оплате труда	160	210	961 010,96	37 189 877,02	2 434 720,18	40 585 608,16
в том числе: заработная плата	161	211	739 387,33	28 566 424,10	1 940 102,25	31 245 913,68
прочие выплаты	162	212	1 800,00	-	-	1 800,00
начисления на выплаты по оплате труда	163	213	219 823,63	8 623 452,92	494 617,93	9 337 894,48
Приобретение работ,услуг	170	220	770 174,50	3 532 174,21	1 374 602,33	5 676 951,04
в том числе: услуги связи	171	221	-	28 398,00	-	28 398,00
коммунальные услуги	173	223	-	2 497 282,95	-	2 497 282,95
работы, услуги по содержанию имущества	175	225	28 732,50	806 132,62	789 182,57	1 624 047,69
прочие работы, услуги	176	226	741 442,00	200 360,64	585 419,76	1 527 222,40
Прочие расходы	250	290	25 806,00	438 067,49	2 000,00	465 873,49
Расходы по операциям с активами	260	270	20 992,00	1 188 208,56	7 136,60	1 216 337,16
в том числе: амортизация основных средств и нематериальных активов	261	271	-	1 089 581,06	-	1 089 581,06
расходование материальных запасов	264	272	20 992,00	98 627,50	7 136,60	126 756,10
Чистый операционный результат (стр.301-стр.302 + стр.303); (стр.310 + стр.380)	300		-	-1 298 466,91	510 821,87	-787 645,04
Операционный результат до налогообложения (стр.010-стр.150)	301		-	-1 298 466,91	510 821,87	-787 645,04
Операции с нефинансовыми активами (стр.320 + стр.330 + стр.350 + стр.360)	310		-	402 275,92	111 225,90	513 501,82
Чистое поступление основных средств	320		-	341 940,09	-	341 940,09
в том числе: увеличение стоимости основных средств	321	310	-	1 431 521,15	-	1 431 521,15
уменьшение стоимости основных средств	322	410	-	1 089 581,06	-	1 089 581,06
Чистое поступление материальных запасов	360		-	60 335,83	111 225,90	171 561,73
в том числе: увеличение стоимости материальных запасов	361	340	20 992,00	158 963,33	118 362,50	298 317,83
уменьшение стоимости материальных запасов	362	440	20 992,00	98 627,50	7 136,60	126 756,10
в том числе: увеличение затрат	371	x	-	42 348 327,28	3 818 459,11	46 166 786,39
уменьшение затрат	372	x	-	42 348 327,28	3 818 459,11	46 166 786,39
Операции с финансовыми активами и обязательствами (стр.390-стр.510)	380		-	-1 700 742,83	399 595,97	-1 301 146,86
Операции с финансовыми активами (стр.410 + стр.420 + стр.440 + стр.460 + стр. 470 + стр.480)	390		-	-1 700 742,83	399 595,97	-1 301 146,86
Чистое поступление средств учреждений	410		2 360,57	-19 388,73	399 595,97	382 567,81
в том числе: поступление средств	411	510	1 800 241,97	41 302 440,33	4 329 280,98	47 431 963,28
выбытие средств	412	610	1 797 881,40	41 321 829,06	3 929 685,01	47 049 395,47
Чистое увеличение дебиторской задолженности	480		-2 360,57	-1 681 354,10	-	-1 683 714,67
в том числе: увеличение прочей дебиторской задолженности	481	560	3 041 318,96	51 750 323,09	4 925 857,98	59 717 500,03
уменьшение прочей дебиторской задолженности	482	660	3 043 679,53	53 431 677,19	4 925 857,98	61 401 214,70
Операции с обязательствами (стр.520 + стр.530 + стр.540)	510		-	-	-	-
Чистое увеличение прочей кредиторской задолженности	540		-	-	-	-
в том числе: увеличение прочей кредиторской задолженности	541	730	1 647 473,25	42 170 838,11	4 119 265,01	47 937 576,37
уменьшение прочей кредиторской задолженности	542	830	1 647 473,25	42 170 838,11	4 119 265,01	47 937 576,37

Руководитель ____________________
«31»декабря 2016г. (подпись)

Главный бухгалтер ________________

«31»декабря 2016г. (подпись)

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

Роналдиньо Казанны ошатты

Бу елларда Казан футбол җанатарларына чып-чын бүләк ясады: Татарстан башкаласына Роналдиньо белән Джей-Джей Окоча килде. Футболның тере легендалары 13-14 май көнне FIFA 2017 Конфедерация Кубогы паркын ачты. Әлеге парк Мәскәү белән Сочи халкын сөендерергә өлгерде инде.

Алисә САБИРОВА

Роналдиньоны без «Барселона» белән «Милан» командасы уенчысы буларак беләбез. Моңа өстәп әле ул – Футбол буенча дөнья чемпионы (2002), Конфедерация Кубогы иясе (2005) һәм, FIFA фикеренчә, дөньяның иң яхшы футболчысы (2004, 2005). Джей-Джей Окоча исә кайчандыр Нигерия җыелмасының ярымсакчысы булган. Ул – Африка милләтләре Кубогы иясе (1994), Олимпия чемпионы (1996).

Чит ил футбол йолдызларыннан тыш, паркка Россия җыелмасының элеккеге капитаны, 2018 елда булачак Футбол буенча дөнья чемпионаты илчесе Алексей Смертин белән Казан «Рубин»ы составында ике тапкыр Россия чемпионы булган Роман Шаронов та килгән иде. Соңгысын җанатарлар парк ачылышының икенче көнендә күрүгә иреште.

Казан Үзәк стадионының моның кадәр халыкны күргәне юк иде әле. Олысы да, кечесе дә, хәтта әбиләр дә футбол легендаларын үз күзләре белән күрергә, ә бәхет елмайса, алар белән фотога төшәргә дип килгән иде. Паркка керүнең ирекле булуы да кеше агымының күплегенә этәргеч булгандыр.

Кунакларны Казан мэры Илсур Метшин шәһәр белән таныштырды.

– Дөньяның танылган футболчыларын кунак итү – безнең өчен зур дәрәҗә. Без бер айдан – Конфедерация Кубогын, ә бер елдан Футбол буенча дөнья чемпионатын кабул итәчәкбез. Казан – гаҗәеп зур футбол бәйрәмен үткәрүче шәһәр булуына чиксез шатмын. Мин сезгә, казанлылар, йөрәгегез һәм елмаюларыгыз белән чемпионатның һәм Конфедерация Кубогының иң кунакчыл шәһәре икәнлегезне күрсәтергә өндим. Футболга ура! – дип сәламләде чит ил кунакларын һәм шәһәр халкын Илсур Метшин.

Парк ачылышы алдыннан Роналдиньо белән Окоча Казан Кремле буйлап сәяхәт итте һәм «Казан-Арена» стадионында туп тибәргә дә өлгерде.

– Казан – матур шәһәр, монда кызлар да бик гүзәл икән. Мине җылы каршы алдылар. Кайчан да булса Казанда җанатарларым өчен берәр матч уткәрәсем килә, – ди Бразилия уенчысы.

Сәхнәгә ул 2005 елда үз командасы белән откан Конфедерация Кубогын тотып чыккан иде.

Конфедерация Кубогында Роналдиньо, бер команда өчен дә җан атмаячакмын, ди.

– Беркем өчен дә җан атмыйм, ләкин мин яхшы, онытылмас уен көтәм, – ди Роналдиньо.

Бу вакытта җанатарлар, түземсезләнеп, футболчылардан автограф сорый иде. Илсур Метшин исә нәни җанатарлар автограф өчен сузган фотоларны Роналдиньо, Окоча һәм Смертинга тапшырып барды. Шәһәр мэры кулыннан футбол йолдызларының имзасын алган малайларның башлары шунда ук күккә тиде.

– Казанда булу – минем өчен зур дәрәҗә. Мин дә, Роналдиньо кебек, Конфедерация Кубогында катнаштым. Кызганыч, иң зур бүләкне оту безгә насыйп булмады. Ләкин анда катнашу тәҗрибәсе искиткеч иде. Конфедерация Кубогында ярышкан һәр команда инде үз иленең чемпионы. Быел Кубокны кем алуына карамастан, ул һичшиксез моңа лаеклы, – диде Джей-Джей Окоча.

Паркта тәкъдим ителгән аттракционнар да тик тормады. Аларда үз көчен сынап караганнарга купонга махсус тамга ябыштырдылар. Ул купонны соңыннан төрле истәлекле бүләкләргә алыштырып була иде. Иң зур бүләк – Конфедерация Кубогына бушлай билет булды.

Роналдиньо белән Окочадан соң иң зур чират чемпионат символы булган «Забивака» атлы бүрегә сузылды. Футбол йолдызларыннан аермалы буларак, аның тән сакчылары юк. Шуңа да җанатарлар аның белән рәхәтләнеп фотога төште, кочаклашты, «бишне биреп» күреште. «Робокипер» исемле капкачы-робот та паркка килүчеләрнең яраткан уены иде. Бирегә, ничек тә роботны алдалап, капкага туп кертергә кирәк. Ни кызганыч, роботны ирләр җиңә алмады, ә билдән түбән малай-шалайлар рәхәтләнеп туп кертте. Аларга карагач, Россиянең футбол киләчәгенә өмет бар икән әле дисең.

Исегезгә төшерәбез, Конфедерация Кубогы матчлары Казан, Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Сочи шәһәрләрендә узачак. Казанда 18 июньдә Португалия – Мексика, 22 июньдә Германия – Чили, 24 июньдә Мексика – Россия уеннары булачак. 28 июнь көнне без ярымфинал матчын кабул итәчәкбез.

Сынау матчы

17 май көнне «Казан-Арена» стадионында Казан «Рубин»ы Мәскәүнең ЦСКА футбол командасы белән очраша. Матч 19.30 сәгатьтә башлана. Әлеге уен Конфедерация Кубогы алдыннан тест матчы булачак. Шуңа да аны оештыру Кубок барышына тәңгәл китереп эшләнелә.

–Иң беренче чиратта җанатарның шәхесен билгели торган системаның эшчәнлеген карачакбыз. «Соңгы миль» эшчәнлеген сынаячакбыз, ягъни стадион янәшәсендәге территорияне, юл хәрәкәтен тәртипкә китерәбез. Күзәтүче корылмаларның эшчәнлеген карыйбыз. Әлеге матч стадионның никадәр әзер булуын күрсәтәчәк. Конфедерация Кубогы вакытында сораулар тумас дип уйлыйм, – диде Татарстан Республикасының яшьләр эшләре һәм спорт министры урынбасары Алмаз Мингулов.

Матч көнендә 17.30-23.30 сәгатьләр аралыгында «Казан-Арена» территориясендәге юллар өлешчә ябылачак. Җәмәгать транспортлары да өлешчә туктатыла.

– 5, 6нчы трамвайлар график буенча эшләячәк. Ләкин алар «Адоратский» белән «Ветеринария академиясе» аралыгындагы тукталышларда туктамаячак. Троллейбуслар исә бөтенләй йөрмәячәк. Җанатарларга стадионга бару уңайлы булсын өчен, «Энергетика университеты» тукталышыннан «Савиново» сәүдә комплексы»на кадәр өстәмә автобус маршруты булдырыла. Шулай ук Ямашев проспекты, Чистай, Сибгат Хәким урамнарында җәяүлеләр өчен махсус зона бүлеп биреләчәк, – диде Казан шәһәре Башкарма комитетының спорт проектлары бүлеге җитәкчесе Роман Ивачев.

Матчка алынган билетлар җәмәгать транспортыннан бушлай файдалану хокукын бирми.

Уен барышында Казан урамнарындагы тынычлыкны 2500 полиция һәм Росгвардия вәкиле саклаячак. Шулай ук Казан кунаклары өчен ун өстәмә машина кую урыны булдырылачак. Алар хакында һәм юл йөреше буенча башка сораулар турында ЮХИДИ хезмәткәрләреннән дә белешеп була.

Исегезгә төшерәбез, матчка бару өчен билет һәм җанатар паспорты булырга тиеш. Моның өчен башта rubinfans.ru сайтына кереп теркәлергә, 11 саннан торган код алырга, аның ярдәмендә fan–id.ru сайтында гариза тутырырга кирәк. «Родина» кинотеатры һәм Четаев урамы, 10нчы йорт адреслары буенча җанатар паспортын алып була. Матч көнне җанатар паспортын алу өчен өстәмә пункт та эшләячәк.

МАТЧ ВАКЫТЫНДА ӨЛЕШЧӘ ЯБЫЛАЧАК УРАМ ИСЕМНӘРЕ

Сибгат Хәким урамы (Әмирхан проспектыннан алып Чистай урамына кадәр);
Чистай урамы (Абдулла Бичурин урамыннан Ямашев проспектына кадәр, Абдулла Бичурин урамы ягыннан барганда);
Ямашев проспекты (Адоратский урамыннан Себер трактына кадәр);
Гаврилов урамы (Чуйков урамыннан Чистай урамына кадәр);
Академик Арбузов урамы (Журналистлар урамыннан Ямашев проспектына кадәр, Журналистлар урамы ягыннан барганда).

Шәһри КАЗАН

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)

www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

Бу санның тиражы – 1646. Гомуми тираж – 6043.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 712. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+

Сатудагы бәясе ирекле

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы.
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы